КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 сентябрь г.Казань № 872

Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру һәм финанслар белән тәэмин итү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификаты турында» 2019 елның 18 маендагы 619 номерлы, «Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуга бәйле чыгымнарны каплау максатларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 18 маендагы 620 номерлы, «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне;

Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуга бәйле чыгымнарны каплау максатларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү кагыйдәләрен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин